**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 елның 18 ноябре** **№122**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 53 номерлы "Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге «Җир салымы турында" гы 53 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 маддәнең 2 пунктында " (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)»;

5 маддәне үз көчен югалткан дип танырга;

6 маддәгә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«Сайлап алынган җир участогы турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы икенче абзацы 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов ур., 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мөрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт,шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге” башлыгы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге” Советы рәисе Х.Х. Ибәтов